ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» июнь 2026 ел № 465

**“Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе” Федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Арча районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең балаларын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында туклану өчен түләүдән азат итү турында**

“Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе” Федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Арча районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең балаларына ярдәм итү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе” федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Арча районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең балаларын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында туклану өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән)алына торган түләүдән азат итәргә.

2. “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы” МКУ (Э.Н. Ганеева) “Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе” Федераль дәүләт

казна учреждениесенең Арча муниципаль районының төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында Арча районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләренең балаларын уку вакытында тукландыруны оештыруга бәйле чыгымнарны финансларга.

3. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар күрсәтелгән чаралар турында мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү системасы операторы (алга таба - БДСТСО) билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү системасыннан файдалану юлы белән җиткерүне тәэмин итәләр

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына Р.Г.Шәймәрдановага йөкләргә.

Җитәкче Л.И.Абдуллин